Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

# МОНАФИКЪЛЫК КҮРЕНЕШЛӘРЕ

Түбән Кама 2010

بسم الله الرحمن الرحيم

## Кереш сүз

إن الحمد لله نحمده و نستعينه و نستغفره و نعوذ بالله من شرور أنفسنا و سيئات أعمالنا من يهده الله فلا مضل له و من يضلل فلا هادي له و أشهد أن لا إله إلا الله وحده لا شريك له و أشهد أن محمدا عبده و رسوله، أما بعد...

Хакыйкатьтә, иң хәерле сүз — Аллаһ тәгаләнең сүзе, вә иң хәерле юл — пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ юлы. Шушы ике асыл белән өммәтебезнең әүвәлгеләре туры вә хак юлда булдылар. Ул ике асыл, бу дөньяда да, ахирәттә дә кешенең уңышка вә бәхеткә ирешү юлы. Кем дә кем аларга тотынса — туры юлда булды, ә кем алардан ераклашса, читләшсә — ул адашты вә хәсрәткә батты.

**Нифакъның (икейөзлелекнең) тел ягыннан булган төшенчәсе:**

Ислам диненә кадәр булган әүвәлге гарәпләрдә, нифакъ сүзе, Исламны икейөзлелек белән тыштан күрсәтеп, ә эчтән, күңелдә көферлекне яшерү дигән мәгънәдә билгеле булмый.

Шуңа да, бу сүзнең тел ягыннан булган асыл мәгънәсе дә Исламда кулланылган мәгънәгә туры килеп бетми:

Нәфакъ, гарәп сүзе, һәм аларда, бер урыннан икенче урынга чыга торган, җир астыннан казылып ясалган яшерен юлга «нәфәкъ» дип әйтә торган булалар. Әгәр дә  кеше бер төрле хәвеф-хәтәргә юлыкса, җир астындагы шушы яшерен юл белән кача торган була. Моңа Коръәннән түбәндәге аять ишарәли:

(وَإِنْ كَانَ كَبُرَ عَلَيْكَ إِعْرَاضُهُمْ فَإِنِ اسْتَطَعْتَ أَنْ تَبْتَغِيَ نَفَقًا فِي الأَرْضِ أَوْ سُلَّمًا فِي السَّمَاءِ فَتَأْتِيَهُمْ بِآيَةٍ وَلَوْ شَاءَ اللَّهُ لَجَمَعَهُمْ عَلَى الْهُدَى فَلا تَكُونَنَّ مِنَ الْجَاهِلِينَ) الأنعام: ٣٥

Мәгънәсе: **«Әгәр кәферләрнең Исламнан баш тартулары сиңа авыр булса, җиргә тишек тишәргә вә күккә менәр өчен баскыч ясарга көчең җитсә – кәферләргә могҗиза күрсәтер идең. Ягъни җир астына төшеп вә күккә менеп могҗизалар күрсәтсәң дә, иман китерәчәк түгелләр. Әгәр Аллаһ тәгалә теләсә, әлбәттә, аларның һәммәсен дә Коръән юлына җыяр иде, ләкин теләмәде. Шуңа да, җаһилләрдән булма!».**

Билгеле булганча, мондый яшерен җир асты юлын кушаяк[1] һәм кәлтә кебек хайваннар куллана. Әгәр дә алар үзләренә җир астында оя ясыйлар икән, бу ояларына ике яки берничә чыгыш юлы ясыйлар, һәм куркынычка дучар булсалар, шул юлларның берсеннән чыгып кача торган булалар. Ләкин, бер яшерен юлны алар җир өстенә үк казып чыгармыйча, бәлки күренмәсен өчен җирнең өске катламын аз гына алмыйча калдыралар. Ул юл тыштан беркемгә дә күренми, ә инде качар вакыт җитсә, кушаяк аңа җир астындагы оясыннан килеп башы белән аз гына төртә дә, яшерен юлының капкачы ачылып, чыгып кача.

Кушаяк оясының җир өстендә күренеп торган ачык юл тишеген гарәпләр «قاصعاء» «каасыйгаа‘» дип әйтәләр, ә инде яшерен, җир өстендә күренмәгән капланган юл тишегенә «نافقاء» «нәәфикаа‘» дип әйтәләр.

Бәлки, кушаякның ошбу хәйләле сыйфатына охшатып, Ислам динендә дә, үзләрен динле дип баш-

1 Урысча «тушканчик»

калардан чын сыйфатларын яшергән бәндәләрне «монафикълар» дип атыйлар, Аллаһу әгъләм.

**Нифакъның (икейөзлелекнең) Ислам динендә билгеле булган төшенчәсе:**

Мөэминнәрне алдар өчен, Аллаһка ышанмыйча эчендә көферлек яшереп, сүзе вә тышкы кыяфәте белән үзен Ислам динендә һәм иманлы икәнлеген күрсәтүче икейөзле кеше, монафикъ дип атала.

Шулай ук, үзен мөселман дип, әмма ләкин Ислам кушканча гамәл итмәүченең икейөзле монафикъ икәнлегенә, ибен Җәрир Хүзәйфәдән мондый риваятьне китерә:

روى ابن جرير عن حذيفة أنه قيل له: ما النفاق؟ قال:
«الرجل يتكلم بالإسلام و لا يعمل به»

Мәгънәсе: Бервакыт Хүзәйфәдән: «Нәрсә ул нифакъ (икейөзлелек)», – дип соралгач, ул: «Үзе Ислам динендә булган кеше кебек сөйләп, әмма ләкин Исламча гамәл кылмаучы бәндә», – диде[2].

**Бу сыйфат түбәндәге кешеләргә кулланыла:**

**1)** Мөселманнардан куркып, яки мөселманнар арасында фетнә, фәсәд чыгарыр өчен, бозыклык таратыр өчен яки инде ганимәт кебек нинди дә булса дөньяви максатка ирешер өчен Исламны кабул итүен белдерүче кеше.

**2)** Әүвәл чынлап вә дөрес ният белән Исламны кабул итеп, соңыннан Исламнан чыгып мөртәд булган, әмма мөртәдлеген яшереп мөселманнар арасында әүвәлгечә Ислам белән билгеле булып йөргән кеше дә бу сыйфатка керә.

2 Тәһзиб әл-Әсәр

**3)** Шулай ук, бу сыйфат, әти-әнисеннән яки икесенең берсеннән нәсел-нәсәб буенча Исламны үзенә мирас итеп алган, ә инде балигъ булгач иманның барча яки бер генә булса да рөкенен күңеле вә йөрәге белән инкяр итеп, тышкы кыяфәте белән үзен мөселман дип күрсәтүче кешегә дә кулланыла.

Мондый кешеләр үзләрен әти-әниләренә яки әби-бабаларына бәйләп, Исламны үз теләкләре белән түгел, ә бәлки буыннан-буынга күчә торган ниндидер мирас дип кабул итәләр. Бу төр кешеләрнең нәсел вә милләте Ислам белән бәйле булганга җәмгыять шаукымында «мөселман» дип аталса да, аларның күңелләре Исламнан бик ерак. Безнең татарлар арасында моңа мисаллар вә гыйбрәтләр бихисап, Аллаһу мүстәган!

Бу кешеләр күңелләре белән Исламның вә Иманның барча яки кайбер рөкеннәрен инкяр итү сәбәпле, яки инде Аллаһка һәм Аның расүленә буйсынып вә итагать итеп яшәмәү сәбәпле, монафикъ булалар.

Алар Исламга каршы килгән уй-фикерләргә ышанып яши торган булсалар да, башкалар аларны көферлектә гаепләүдән куркып, үзләренең көфер уй-фикерләрен ачыктан-ачык игълан итмиләр.

**4)** Ислам дәүләтләрендә яһүд, нәсара яки мәҗүси кебек гаиләләр, үзләренең диннәрен саклар өчен Исламны кабул итүләре турында игълан итеп, ә инде яшерен генә үз диннәрен тотып Исламга вә мөселманнарга зыян коручы бәндәләр дә ошбу сыйфатка керәләр.

## 🕮 Монафикълык һәм аның куркынычлыгы

Икейөзлелек, ул кеше тормышындагы иң кабахәт холык булып тора, һәм аңа иң кабахәт сыйфатлар керә. Мәсәлән: куркаклык, хаклыкны кабул итмәү, дөнья ләззәтен эстәү, мәкерлек вә хәйләкәрлек, ялагайлык һәм башкаларга ярарга тырышу, сүздә дә, гамәлдә дә ялганлау вә алдашу.

Ислам тарихында һәм хәзер дә, мөселманнарга ирешкән иң зур кайгылар вә бәла-казалар монафикълар сәбәпле булды. Алар мөселманнарның сафларын эчтән җимерергә үзләренең барча мәкерлекләрен кордылар вә коралар. Мөселманнарга монафикъларның хәтәрлеген бәян итеп, саклану юлларын күрергә кирәк. Чөнки, тышкы дошманга караганда, Ислам җәмгыяте эчендә йөргән дошман күпкә куркынычрак вә зарарлырак.

Шуңа да, Аллаһ тәгалә Коръәндә һәм пәйгамбәребез ﷺ үзенең хәдисләрендә монафикълардан да, нифакътан да сакланырга кушты.

## 🕮 Монафикъларның көферлек белән бәйле төрләре

Көферлек белән бәйләгәндә, монафикълар ике төрлегә бүленәләр:

**1)** Яһүд, нәсара, мәҗүси яки коммунистлар кебек бер көфер дине белән бәйле, монафикъларның аерым билгеле диннәре бар.

**2)** Икенче төр монафикъларның аерым билгеле диннәре юк, бәлки алар дөнья малын, рәислекне таләп итүче икейөзле кешеләр. Кайда шушы

нәрсәләрне тапсалар, шунда таба ашкыналар. Үзләренә кирәк файданы мөселманнарда табалар икән – анда ашыгалар, кәферләрдә тапсалар – алар янына ашыгалар. Ягъни бу якка да, теге якка да сикереп йөриләр. Түбәндәге аятьләрдә, мөгаен, ошбу төр монафикълар хакында әйтелүе күздә тотыла:

Мәгънәсе: **«Әлбәттә, монафикъларга рәнҗеткүче каты газап булачагы белән хәбәр бир! Алар мөэминнәрдән башка, кәферләрне дус тоталар. Әйе, ул монафикълар өстенлекне көферләрдән эстиләрме? Бит көч-кодрәт һәм өстенлек фәкать Аллаһ кулындадыр. Әй мөэминнәр! Дөреслектә, сезгә Коръәндә ничә мәртәбә иңдерелде: «Кәферләрнең Коръән аятьләрен инкяр итүләрен яки мәсхәрә кылып көлүләрен ишетсәгез, алар арасында утырмагыз, ягъни аларның бу кабахәт эшләреннән һич тә риза булып тормагыз, Коръән сүзләренә кагылмый торган сүзгә күчкәннәренә чаклы. Әгәр аларның Коръәнгә каршы булган сүзләренә һәм эшләренә риза булып торсагыз, ул вакытта алар җөмләсеннән булырсыз. Шиксез, Аллаһ монафикълар белән кәферләрне һәммәсен җәһәннәмгә җыячак». Әй мөэминнәр! Монафикълар, сезнең хәлегезнең алар файдасына үзгәргәнен көтәдер, әгәр сез Аллаһ ярдәме белән бер шәһәрне, я бер авылны алсагыз, монафикълар: «Әйе, без дә сезнең белән бергә түгел идекме? Безгә дә ганимәт малын бирегез», – диләр, әгәр сугышта кәферләр җиңсәләр, монафикълар: «Әйе, без сезгә мөселманнарның бөтен хәлләрен белдереп тордык түгелме? һәм мөселманнарны җиңү өчен сезгә ярдәм күрсәттек түгелме? Безгә дә өлеш бирегез», – диярләр. Аллаһ Кыямәт көнне**

**сезнең белән монафикълар арасында булган хәл белән хөкем итәр. Аллаһ хак мөэминнәрне имансыз итәргә кәферләргә һич тә юл ачмады, ягъни кәферләр Коръән белән гамәл кылучы мөэминнең иманын алырга кадир булмаслар. Әлбәттә, монафикълар Аллаһны алдыйбыз дип уйлыйлар, Аллаһ исә аларны дөньяда һидәяттән, ахирәттә Җәннәттән мәхрүм итеп алдаучыдыр. Әгәр монафикълар намазга торсалар кешеләргә рияланып, ялкауланып кына торалар, һәм Аллаһны бик аз гына зикер итәләр. Монафикълар, мөэминнәр белән кәферләр арасында ике якның беренә була алмыйча, сикереп йөриләр. (Аларны кәферләр дә, мөэминнәр дә яратмый, чөнки дөньяда иң яман кеше монафикътыр.) Әгәр Аллаһ берәүне адаштырса, син аңа туры юлны һич тә тапмассың. Әй мөэминнәр! Мөэминнәрдән башка, кәферләрне дус тотмагыз, ягъни дусларыгыз мөэминнәр генә булсын! Әллә Аллаһ сезне газап кылсын өчен, дәлил булуны телисезме? Кәферләргә дус булып монафикъларның кайтачак урыны, шиксез, җәһәннәмнең иң түбән катлавындадыр, аларны җәһәннәмнән коткарырга ярдәмче таба алмассың. Мәгәр, җәһәннәм астында калмаслар, монафикълыктан ныклап тәүбә итсәләр, күңелләрен вә гамәлләрен төзәтсәләр, Аллаһның Коръәндәге хөкемнәренә ябышсалар һәм диннәрен ихлас күңелдән Аллаһ ризасы өчен генә тотсалар, ул чагында алар мөэминнәр белән бергә булырлар. Аллаһ тиздән мөэминнәргә олы әҗер – Җәннәт нигъмәтләрен бирер».** (Әл-Әнгам: 138-146)

**Бу аятьләрдән кыскача гына түбәндәгеләрне әйтеп узарга мөмкин:**

**А)** Ислам диненнән көлү, яки аннан көлүчеләрдән ризалык белгертү булырга тиеш түгел. Көферлекне дөрес дип тану, ул үзе көферлек, ә инде үзеңне мөэмин-мөселман дип әйтеп көферлекне өстен кую, ул – монафикълык.

**Б)** Мөселманнар үзләренә мөэмин-мөселманнардан башкаларны дус вә иптәш итеп алырга тиеш түгелләр. Кәферләр көчле дип аларны дус итү, Исламга вә мөселманнарга зарар гына китерә, һәм монафикълыкның ачык күренеше.

Монафикъларның һәм кәферләрнең уй-фикерләре бер булган өчен, аларның җәһәннәмдә дә бергә җыелулары Аллаһ тәгаләнең гадел хөкеме булып тора.

Аллаһ тәгалә бу аятьләрдә, мөэминнәр белән кәферләр арасында бер яктан икенче якка сикереп йөрүче монафикъларның җиде сыйфатын бәян итте:

**Беренче сыйфат:** Бу төр монафикълар үзләренең табышын, оста аучы җәнлекне аулаган кебек аулыйлар. Әгәр дә мөэминнәр җиңсә, алар: «Без сезнең белән бергә булмадык мени?», – дип, үзләренә ганимәттән өлеш чыгаруны таләп итәләр. Ә инде әгәр дә Аллаһ тәгалә теләгән бер-бер хикмәт өчен җиңү кәферләргә насыйп булса, ул вакытта монафикълар алар янына килеп: «Без сезгә мөселманнарның бөтен хәлләрен белдереп тордык түгелме? Һәм мөселманнарны җиңү өчен сезгә ярдәм күрсәттек түгелме?», – дип, сугышта табылган табыштан үзләренең өлешләрен һәм дә рәислек вә урыннар таләп итәләр.

**Икенче сыйфат:** Әгәр дә, монафикълар намазга торсалар, ялкауланып, кешеләргә күрсәтер өчен генә торалар. Чөнки алар намазны Аллаһ кушканга түгел, ә бәлки башкалар аларның намаз укымаганнарын күреп, икейөзлелекләрен белерләр дип, куркып кына намазга басалар.

**Өченче сыйфат:** Алар Аллаһны һәрвакытта да зикер итеп искә алмыйлар, ә бәлки мөэминнәр каршында риядан гына аз вакытта зикер итәләр. Чөнки аларның йөрәкләре икейөзлелек белән тулган, ә Аны һәрдаим зикер итү, йөрәге Аллаһка мәхәббәт белән тулган мөэмин-мөселманнан гына чагыла.

**Дүртенче сыйфат:** Алар үзләренә кәферләрне дус вә иптәш итеп алалар. Чөнки монафикълар өстенлекне вә көч-куәтне кәферләрдән эстиләр, ә бу нәрсәләрнең барсы да Аллаһ тәгалә кулында икәнлеген белмиләр.

**Бишенче сыйфат:** Монафикълар кәферләр белән бергә мәҗлесләрдә, аларның көферлек сүзләрен һәм Ислам диненнән көлүләрен тыңлап утыралар. Алдагы аятьләрдән билгеле булганча, Аллаһ тәгалә мөэминнәрне мондый утырышлардан тыйды.

**Алтынчы сыйфат:** Монафикълар, мөэминнәр белән кәферләр арасында яктан якка сикереп йөреп, Аллаһ тәгаләне алдыйбыз дип уйлыйлар. Ләкин, Аллаһ тәгалә гадел хөкеме белән аларга җәза биргәнчегә кадәр кичектереп тора, һәм аларның мәкерлекләрен үзләренә кайтара.

**Җиденче сыйфат:** Монафикъларның иман ягыннан да, көферлек ягыннан да төпле карашлары юк, шуңа да алар шәһвәтләре кайсы якка тартылса, шул якка юнәләләр.

## 📖 Икейөзлелеккә этәрүче сәбәпләр

**1)** Дөнья мәнфәгатләрен эстәү.

**2)** Үзе, малы һәм дөнья мәнфәгате юкка чыгуыннан курку.

**3)** Исламга һәм мөселманнарга каршы явызлык эстәү.

**4)** Нәсел-нәсәбе буенча мөселман булып, ләкин йөрәгендә Аллаһка ышанмыйча, башкаларның аны мөселман түгеллеген белүдән курку.

## 📖 Нифакъның дәрәҗәләре

Көферлекнең берсеннән-берсе түбәнрәк вә кабахәтрәк дәрәҗәсе булган кебек, нифакъның да берсеннән-берсе түбәнрәк вә кабахәтрәк дәрәҗәләре бар.

Нифакъның дәрәҗәләре түбәнлектә дә, кабахәтлектә дә һәм юньсезлектә дә көферлек дәрәҗәләре белән туры килә. Боларга өстәп, монафикъның, Ислам өммәте эченнән мөселманнарның ышанычын алып, хыянәт вә ялган кулланып Исламга вә мөселманнарга каршы корган мәкерлекләре, гакыйдәләренә карата зарарлары, Ислам шәригатен вә хөкемнәрен бозуга салган тырышлыклары, һәм дин дошманнарына хезмәт итүләрен әйтергә була.

Мөселманнар тарафыннан үзенә файда эстәүче, яки үзенең нәфсе, малы һәм гаилә әһелләре өчен куркучы монафикъка караганда, Исламга һәм мөселманнарга мәкерлек эстәп, төрле юллар белән аларга зыян, диннән читләштерү һәм Ислам

дәүләтләрен юкка чыгару өчен тырышкан монафикъ күпкә куркынычрак.

Ә инде шушы нәрсәләрне оештыруның башында торган монафикълар, тагын да куркынычрак.

Шуңа да, икейөзлелек көферлектән дә кабахәтрәк һәм аннан да күбрәк зыян китерә.

Бу әйтеп узганнар, зур нифакъ дип атала, һәм бу төрле монафикълар асыл хәлләрендә кәферләр. Бәлки, тышкы кыяфәтләре белән генә Исламга бәйлеләр.

## 🕮 Кечкенә нифакъ (монафикълык)

Шулай ук, кешене Исламнан көферлеккә чыгармый торган монафикълык бар. Бу гамәлне эшләгән кеше, гөнаһлы вә бозык кеше була. Яки инде аның изгелек итеп кылган гамәле юкка чыга һ.б. Бу төрле нифакъ **«кечкенә нифакъ»,** – дип атала.

Диннең асыл рөкеннәренә һәм гакыйдәсенә тимичә, кешеләргә үзенең тышкы кыяфәтен, гыйбадәтен күрсәтер өчен эшләүче, ул **кечкенә нифакълы монафикъ** була.

Шулай ук, кем кешеләргә ялганлап, алар арасында үзен ышанычлы кеше итеп белгертә, ә инде үзенә кирәк булганда аңа бирелгән ышанычка хыянәт итә икән, бу да **кечкенә нифакълы монафикъ** була.

Берәү үзенә карата башкаларның кызгануын вә шәфкатьлеген алыр өчен фәкыйрьлек вә мескенлек күрсәтә икән, ул да **кечкенә нифакълы монафикъ** була.

Яки, әгәр дә икенче берәүгә мәхәббәт вә дуслык белгертеп, ә эчендә аңа карата дошманлык булса, бу кеше дә **кечкенә нифакълы монафикъ** була.

Һәм шушы сурәт тә, кечкенә нифакълы монафикъка бик күп мисаллар китерергә мөмкин.

Монафикъның иң зур хәйләсе, сүздә дә һәм күренә торган тышкы гамәлләрдә дә ялганлау. Чөнки ул ялганлап кешеләр арасында ышаныч яулый, һәм аңа башкалар үзләренең мал-мөлкәтләрен, серләрен, намусларын, вәгъдәләрен вә килешүләрен тапшыралар. Әгәр дә инде ул, аңа ышанып тапшырылган нәрсәгә хыянәт итә икән, бу аның монафикълыгының җимеше була, һәм башкалар бу сыйфатны белмәсен өчен, бәхәс вә низагларда ялган антлар кыла башлый, мәсәлән: әгәр дә ике кеше казый каршында бәхәсләшсә, монафикъ: «Бу кеше миңа 1000 сум бирергә тиеш», – дип, ялган ант итә һәм ялган шаһитләр белән исбатлый. Яки, монафикъ берәрсенә нәрсә булса да тиеш булса һәм тегесенең бернинди дә шаһитлек кылучылары булмаса, казыйга: «Мин аңа бернәрсә дә тиеш түгел», – дип ялган ант кыла.

Шулай итеп, күпчелек хәлләрдә, монафикъта биш кабахәт сыйфат җыела:

**1)** Сүздә дә, гамәлдә дә ялганлау.

**2)** Вәгъдә дә тормау.

**3)** Килешүне мәкерле рәвештә бозу.

**4)** Әманәткә хыянәть итү.

**5)** Бәхәс вә низагларда ялганлау.

Бу сыйфатлар барсы да пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләрендә бәян ителде:

Бохарида[3] һәм Мөслимдә[4] Әбү Һүрайрадан ﷺ риваять ителгән хәдистә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Монафикъны өч билгедән аералар: сөйләсә — алдый, вәгъдә итсә — (вәгъдәсен) боза, әманәт тапшырсалар — хыянәт итә».***

Бу хәдиснең Мөслим[5] китергән икенче риваятендә пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«...хәтта, әгәр ул ураза тотса да, намаз укыса да, һәм үзен мөселман дип икърар итсә дә».***

Икенче риваятьтә: ***«Әгәр дә килешү төзесә — мәкерле рәвештә боза, бәхәсләшсә — азгын рәвештә ялганлый»,*** – диелде[6].

## 🕮 Сахәбәләрнең нифакътан саклanулары

Зур һәм кечкенә нифакъ кешедә иң кабахәт сыйфатларны күрсәткәнлектән, пәйгамбәребезнең ﷺ сахәбәләре үзләрендә бу сыйфатлар булудан яки ялгыш кына булса да андый гамәл кылудан бик тә нык куркалар вә саклананалар иде.

Ибен Гасәкир үзенең тарих китабында Хүзәйфә бин әл-Йәмәннән[7] ﷺ риваять итүенчә, (Хүзәйфә) әйтте: «Мин мәчеттә утырып торганда Гомәр ﷺ минем яннан узып барышлый: «Әй Хүзәйфә! Фәлән кеше вафат булды, җеназасына бар», – диде. Ул мәчеттән чыгып барышлый миңа таба борылып карады, һәм мин урынымнан кузгалмыйча уты-

3 Бохари 33
4 Мөслим 59
5 Мөслим 59
6 Бохари 34
7 Билгеле сахәбә, пәйгамбәребезнең ﷺ «сер хуҗасы», чөнки расүлебез аңа монафикъларның исемнәрен әйткән була.

ра бируемне күргәч, ни өчен утырып калганымны аңлады. Шуннан соң минем яныма яңадан килеп: «Әй Хүзәйфә! Аллаһ исеме белән сорыйм, мин ул (монафикълар) кавеменнәнме?», – диде. Мин аңа: «Аллаһ белән ант итәм. Юк!», – дидем. Шуннан соң Гомәрнең күзләреннән яшьләр агып чыкты».

Бохарида[8] килгән риваятьтә, ибен Әбий Мүләйкәһ әйтте: «Мин расүлебезнең ﷺ утыз сахәбәсен күрү хөрмәтенә ирештем. Алар барсы да үзләре өчен нифакълыктан куркалар иде, һәм берсе дә: «Минем иманым Җәбраил яки Микәилнеке кебек», – дип әйтмиләр иде».

Сахәбәләрнең нифакътан курыкканнарын, ошбу өч нокта белән әйтеп узарга мөмкин:

**1)** Үзләренең холыкларына кечкенә нифакъның бер генә булса да сыйфаты эләгүеннән бик тә нык курка торган булганнар.

**2)** Үзләренең иманнары пәйгамбәребезнең ﷺ иманыннан түбәнрәк булудан курка торган булганнар.

**3)** Дөнья малына вә дәрәҗәсенә ирешүдә Ислам белән файдаланудан курка торган булганнар.

Боларның барсына да сахәбәләрнең тормышы шәһидлек итә.

Мөслимдә[9] килгән риваятьтә, Әбү Рибгый Хәнзәлә әл-Үсәйди ﵁ әйтте: «Бервакыт мин Әбү Бәкерне ﵁ очраттым, ул миннән: «Әй Хәнзәлә, ничек яшисең?», – дип сорады. Мин аңа: «Хәнзәлә монафикъка әйләнде», – дидем. Ул: «СөбхәнАллаһ! Син нәрсә сөйлисең?!», – дип кычкырды. Мин: «Без Җәннәт һәм Җәһәннәм турында искә төшерүче Аллаһ Илчесе ﷺ янына килгәндә, әйтерсең лә анысын да, монысын

8 36нчы бәб
9 2750

да күрәбез. Ә без аның яныннан киткәч, үзебезнең хатыннарыбыз, балаларыбыз һәм тормыш өчен кәсеп итү белән мәшгуль булып күп нәрсәне онытабыз!», – дидем. Әбү Бәкер ﵁ әйтте: «Ләкин, Аллаһ белән ант итәм, мондый хәл безнең белән дә була!». Шуннан соң, без Әбү Бәкер белән Аллаһның Илчесе ﷺ янына килдек һәм мин аңа: «Хәнзәлә монафикъ булды, әй Аллаһның Илчесе ﷺ!», – дидем. Ул ﷺ: ***«Бу нәрсәдә күренә?»***, – дип сорады. Мин: «Әй Аллаһның Илчесе, без сиңа килгәч, син безгә Җәнәт белән Җәһәннәм турында сөйлисең, без әйтерсең лә аларны үз күзебез белән күргән кебек булабыз, ә инде синең яныңнан киткәч, хатыннарыбыз, балаларыбыз һәм ризык табу белән шөгыльләнә башлыйбыз, һәм күп нәрсәне онытабыз!», – дидем. Аллаһның Илчесе ﷺ мине тыңлагач, әйтте: ***«Минем җаным, Аның кулында булган зат белән ант итәм! Әгәр сез даими минем янда булган вакыттагы кебек халәттә булсагыз, һәм Аллаһны һәрвакыт зикер итсәгез, кайда гына булсагыз да, — юлдамы, түшәктәме, — фәрештәләр сезнең кулыгызны кысарлар иде, ләкин, әй Хәнзәлә, һәр нәрсәнең үз вакыты бар»,*** – дип, бу сүзләрне өч тапкыр кабатлады».

Бу хәдистән безгә күренгәнчә, Әбү Бәкер ﵁ һәм Хәнзәлә ﵁ үзләрендә нифакъ тамгасы булуыннан куркып һәм ошбу сәбәпле дөнья малы белән шөгыльләнеп, Аллаһны һәм ахирәтне зикер итүдә гафил вә ваемсызга әйләнүдән курыктылар.

Мөхәммәт бин Зәйд ﵁ сүзләреннән риваять ителә: Бервакыт кешеләр аның бабасы Габдуллаһ бин Гомәргә ﵄ әйттеләр: «Дөреслектә, без патшабызга кергәч, аларга аннан чыкканнан соң сөйләгәннең

киресен сөйлибез». Моңа ул: «Без моны икейөзлелек дип саный идек!», – диде.[10]

Әл-Хәрис бин Әбий Үсәмә ﵁ әйтте: «Мин Габдуллаһ бин Гомәр ﵁ янына килдем дә: «Без үзебезнең имамнарыбыз янында утырганда алар кемгә дә булса берәрнәрсә сөйләсәләр, без аларның сүзләре дөрес булмаганлыгын белә торып, хак вә дөрес дип раслый идек», – дидем. Ул миңа: «Без моны монафикъ-лык дип саный идек, ә сездә нәрсә дип саналганын белмим», – диде[11].

Бу кечкенә нифакъ, әмма ләкин ул зур гөнаһлардан да исәпләнергә мөмкин. Ләкин шуңа карамастан, ул көферлеккә керми.

Шулай да, ахирәт галимнәре үзләрен солтаннардан вә түрәләрдән тыярга, алар белән аралашудан, буталышудан сакларга тиешләр. Чөнки, әгәр дә гыйлем ияләре халыкны изгелеккә өндәп, ә үзләре түрәләр вә байлар янында ялагайланып тискәресен сөйли торган булсалар һәм аларны бозыклыктан тыймасалар вә изгелеккә боермасалар, болар барсы да кечкенә нифакъка китерә торган нәрсәләр.

Кайбер гыйлем әһелләре патшаларга вә хөкүмәт башлыкларына керүне тыялар иде. Ибен әл-Җәүзий бу хакта үзенең «Тәлбис әл-иблис» китабында болай дип әйтеп узды:

«Гыйлем ияләренең патшалар һәм хөкүмәт башлыклары белән буталулары, аларга ялагайланулары вә ярарга тырышулары, шулай ук, белә торып аларны бозыклыктан тыймаулары, һәммәсе дә иблиснең гыйлем ияләрен алдаганлыгын күрсәтә. Бәлки, алар дөнья малын эстәп, рөхсәт ителмәгән нәрсәләрне дә

10 Бохари 7178

11 Әт-Табәри «Тәһзиб әл-Әсәр»

патшаларга рөхсәт итәргә мөмкиннәр, һәм шушының белән өч төр кеше бозыклыкка керә:

**1)** Хөкүмәт башлыгы. Ул: «Мин дөрес вә хаклыкта булса кирәк, чөнки мин дөрес булмасам, миңа килеп йөргән вә минем малымнан ашаган гыйлем ияләре мине тыярлар иде», – ди.

**2)** Гади кеше. Ул: «Бу хөкүмәт башлыгы үзе дә, малы да һәм эшләгән эшләре дә ярыйсы булса кирәк. Чөнки теге гыйлем иясе аның яныннан китми», – ди.

**3)** Гыйлем иясе. Ул ошбу гамәлләре белән үзенең динен боза.

Кыскасы, хөкүмәт башлыкларына керүдә бик зур куркынычлык бар. Чөнки кергән чакта яхшы ният белән керә торган булса да, ләкин аларның юмартлык күрсәтүе белән, яки алардан нәрсә булса да эстәп, гыйлем иясе аңа ялагайланып, бозыклыктан да тыймыйча калырга мөмкин».

Суфиян әс-Сәүрий ﵁ әйтә торган иде: «Мин, патшаларның түбәнсетүеннән түгел, ә алар миңа юмартлык күрсәтүләреннән һәм шушы сәбәпле минем йөрәгем аларга авышуыннан куркам».

Әбү Һүрайрадан ﵁ риваять ителүенчә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Кем сахрада яшәсә — каты күңеллегә[12] әйләнә, кем аучылык белән артык мавыкса — гафил була[13], ә кем патшаларга йөрсә — фетнәгә бата. Кеше патшаларга якынайган саен, Аллаһ тәгаләдән ерагая»[14].***

Сүфиян бин Гуяйнәдән риваять кылынуынча, Әбү Хәзим әйтте: «Хакыйкатьтә, галимнәр патшалар белән очрашудан качалар иде, ә патшалар галимнәр

12 Каты бәгырьле, мәрхәмәтсез

13 Аллаһны зикер итүдә, гыйбадәттә читләшәсең

14 Мүснәд Әхмәд, Силсилә әс-сахихә - 1272

артыннан йөриләр иде. Бүгенге көндә гыйлем ияләре патшаларның ишек төпләрен таптыйлар, ә патшалар алардан качалар»[15].

Хүзәйфә ﷺ әйтте: «Фетнә урыннарыннан сак булыгыз!». Сорадылар: «Нәрсә ул фетнә урыннары, әй Әбү Габдуллаһ?», – дип. Ул әйтте: «Патшаларның ишекләре. Сезнең берәрегез җитәкче янына кереп аның ялганын дөрескә чыгарыр, һәм аңарда булмаган нәрсәне әйтер»[16].

Габдуллаһ бин Мәсгуд ﷺ әйтте: «Хакыйкатьтә, патшаларның ишек төпләрендә кызыгырлык әйберләр бар, ләкин, Аллаһ белән ант итеп әйтәм, сез аларның дөнья малларыннан һичнәрсәләренә дә ирешә алмассыз, яки ирешсәгез алар һичшиксез сезнең динегезгә дә шулай ук ирешәчәкләр (динегезне бозачаклар)»[17].

Яхъя бин Әбий Кәсир әйтте: «Гыйлем ияләре алар тоз кебек, әгәр дә берәр нәрсә бозылса ул тоз белән төзәлә, ә инде тоз бозылса ул һичнәрсә белән дә төзәлмәячәк»[18].

Шулай ук, әл-Әгъмәш әйтте: «Гыйлем ияләреннән ерак булган патшалар вә җитәкчеләр – иң явызлары вә бозыклары, ә инде иң бозык гыйлем ияләре – патшаларга вә җитәкчеләргә якын булганнары».

Сүфиян әс-Сәүрий болай дип әйтә торган иде: «Мин кешенең дөнья яраткanлыгын, патшаларга һәм байларга ничек сәлам бирүеннән беләдем»[19].

Бервакыт, Хәсән әл-Бәсърий гыйлем ияләренең, җитәкче ибен Һәбиранең ишек төбендә керергә көтеп

15 «Әл-Хүлйә» Әбү Нүгайм
16 Мүсаннаф Габдурраззак
17 Мүсаннаф Габдурраззак
18 «Әл-Хүлйә» Әбү Нүгайм
19 «Әл-Хүлйә» Әбү Нүгайм

утырганнарын күреп, болай диде: «Әгәр дә сез алар-да булган нәрсәләрдән читләшсәгез, ул җитәкчеләр сездә булган нәрсәне эстәрләр иде, ләкин, сез алардагы нәрсәләрне эстисез, шуңа да алар сездәге нәрсәләрдән (гыйлемнән) читләшәләр[20]».

Сәгыйд бин әл-Мүсәйб әйтте: «Әгәр дә берәр галимнең патшага килгәнен күрсәгез, ул галимнән сакланыгыз! Чөнки ул – карак!»[21].

Шулай ук, ахирәт галимнәре фәтвә бирүдә ашыкмыйлар, ә инде фәтвә бирә торган булсалар, иллә-мәгәр аның дөреслегендә бик нык ышанган булсалар гына бирәләр. Алар пәйгамбәребезгә, сахәбәләргә һәм изге сәләфләргә иярәләр.

Габдуррахмән бин Әбий Ләйлә болай диде: «Мин бу мәчеттә пәйгамбәребезнең ﷺ йөз егерме сахәбәсен күрдем. Әгәр дә алардан берәрсе хәдис яки фәтвә сораса, алар ул кешене икенче кардәшләреннән сорарга җибәрәләр иде. Шуннан соң, заманалар үтеп фәтвә вә сорауларга җавап бирүләр безнең вакыттагы кебек, үзләрен гыйлем ияләренә санаган кешеләргә калды. Алар соралган һәрбер мәсьәләгә ашыгып-ашыгып җавап бирә башладылар. Әгәр дә, ул сорауны Гомәр бин әл-Хаттабка бирсәләр, ул аны хәл итәргә киңәшләшер өчен барча Бәдер әһелләрен җыяр иде».

Әл-Хәсән әл-Бәсърий әйтә торган иде: «Аллаһ белән ант итәм! Мөэмин кеше узган тормышы өчен дә, киләсе тормышы өчен дә нифакълыктан курка, ә монафикъ узган вә киләсе тормышы өчен нифакълыктан үзен имин дип уйлый».

20 «Әл-Хүлйә» Әбү Нүгайм

21 «Ихья гулүм эд-дин» әл-Газәли

Шулай ук, ул әйтте: «Кем дә кем икейөзлелектән курыкмый икән, ул – монафикъ».

Шулай ук: «Тел белән йөрәкнең, яшерен гамәл белән ачык гамәлнең, кемгә дә булса керү белән аннан чыгуның капма-каршы килүләре – нифакълыктан», – диде.

Узганнарның барсында да кечкенә нифакъның кайбер сыйфатлары искә алына, ә инде керү белән чыгуга килгәндә, кеше түрәгә яки имамга кергәндә хаклыкны әйтмичә аның ялганын хуплый вә раслый, ә аннан чыккач үзара хаклыкны сөйләгән булып ул түрәне яки имамны гаделсез вә ялган сөйли дип гаепли башлый.

## Пәйгамбәребезнең ﷺ монафикъка биргән чагыштырмалары

**1)** Пәйгамбәребез ﷺ Коръән укыган монафикъны хуш исле, ләкин ачы тәмле рәйхан[22] белән чагыштырды. Ә Коръән укымаган монафикъны начар исле һәм ачы тәмле ханзәлә үләне белән чагыштырды.

Әбү Муса әл-Әшгаридән ﵁ риваять ителүенчә, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Коръәнне укый торган мөэмин хуш исле һәм тәмгә татлы булган лимонга тиң, ә Коръәнне укымый торган мөэмин исе булмаган, ләкин тәме татлы хөрмәгә тиң. Коръән укый торган монафикъ хуш искә ия, ләкин тәмгә ачы булган рәйханга тиң, ә Коръән укымый торган монафикъ хуш исе булмаган һәм тәмгә ачы ханзәләгә тиң»[23].***

---

22 Зәңгәр чәчәк ата торган хуш исле гөл; русчасы: базилик

23 Бохари 5059

**2)** Ибен Җәрир Катәдән мондый риваятьне китерде, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Мөэмин, монафикъ һәм кәфер, каршыларына елга очраган өч кеше кебек. Мөэмин елгага кереп китә дә, икенче ягына йөзеп чыга. Шуннан соң елгага монафикъ кереп китә һәм мөэмин янына якыная башлагач кәфер аңа: «Мин синең өчен куркам, (син батып үләсең бит) миңа таба кире кил!», — дип кычкыра. Мөэмин аңа: «Син миңа таба йөз, монда син котыласың», — дип дәшә. Монафикъ кайсына таба йөзәргә белмичә икесенең арасында югалып, каушап кала һәм батып үлә. Хакыйкатьтә, монафикъ үлгәнче шик-шөбһәдә була»[24].***

Бу хәдис, бер тәгаенле көфер мәзһәбендә булган монафикъның сыйфаты түгел, ә бәлки шик-шөбһәдә булып ихтияры булган монафикъның сыйфатын бәян итә.

**3)** Ибен Җәрир Катәдән мондый риваятьне китерде, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Монафикъ, ике сарык көтүе арасында кычкырып йөрүче сарык кебек. Көтүнең берсен калкулыкта, биектәрәк күргәч алар янына чабып бара да, берәр тамгасыннан танырмын дип карап тора, әмма ләкин берничек тә таный алмый. Шуннан соң, ул икенче көтүне башка калкулыкта, биектәрәк күрә һәм аңа таба чабып китә. Аны да берәр тамгасыннан танырмын дип карап-карап тора, әмма ләкин берничек тә таный алмый»[25].***

Бу хәдис тә, бер тәгаенле көфер мәзһәбендә булган монафикъның сыйфаты түгел, ә бәлки шик-

24 «Җәмигъ әл-әхәдис» әс-Сүюүтый
25 «Җәмигъ әл-әхәдис» әс-Сүюүтый

шөбһәдә булып ихтияры булган монафикъның сыйфатын бәян итә.

**4)** Мөслимдә[26] ибен Гомәрдән ﵁ мондый риваять килде, пәйгамбәребез ﷺ әйтте: ***«Монафикъ, ике сарык көтүе арасында адашып кычкырып йөрүче сарык кебек. Кайсысына ияреп китергә белмичә йә берсенә кушыла, йә икенчесенә кушыла».***

## 🕮 Монафикъларның тәннәрендә чагылган кайбер сыйфатлары

**1)** Әбү Нүгайм «әт-Тыйб»тә Әнәстән мондый риваятьне китерде: ***«Әгәр дә авыру вә чир сәбәбеннән булмаган сары йөзле кешене күрсәгез, аның йөзенең саргаюы Исламга карата булган йөрәгендәге ялганнандыр»[27].***

**2)** Әд-Дәйләмий «әл-Фирдәүс»тә ибен Габбәстән мондый риваятьне китерде: ***«Сары йөзле кешеләрдән сак булыгыз! Әгәр дә аларның йөзләре авыру вә чир сәбәпле сары түгел икән, мөселманнарга карата булган йөрәкләрендәге явызлыктан вә ачудан сары»[28].***

**3)** Әд-Дәйләмий «әл-Фирдәүс»тә Галидән мондый риваятьне китерде: ***«Монафикъ күзләре белән идарә итә (вә алдалый), һәм теләгән вакытында елап күрсәтә»[29].***

---

26 Мөслим 2784
27 «Әл-Җәмигъ әс-сагыйр вә зиядәһ» 1520 (Әлбәний зәгыйфь диде)
28 «Әл-Җәмигъ әс-сагыйр вә зиядәһ» 1208 (Әлбәний мәүдугъ диде)
29 «Әл-Җәмигъ әс-сагыйр вә зиядәһ» 12716 (Әлбәний бик тә зәгыйфь диде)

## 🕮 Икейөзлелек чагыла торган урыннар вә аның күренешләре

Кеше тормышында икейөзлелек чагыла торган урыннар бик күп. Без шуларның бик мөһимнәрен генә искә алып узарбыз:

**Беренчесе:**

Диндәге нифакъ һәм әйткәнебезчә ул икегә бүленә:

**1)** Зур нифакъ. Көферлекне эчтә яшереп, тыштан Исламны күрсәтү.

**2)** Кечкенә нифакъ. Кешеләргә изге гамәлләрне күрсәтеп, аларны ялганлап дөньяви максатка ирешүне эстәү.

**Икенчесе:**

Шымчылык нифакы. Алар бер кеше яки оешма яки дәүләт файдасына төрле ялган вә явызлык кулланып, икейөзлелек киеме кияләр.

**Өченчесе:**

Сәясәттә вә идарә итүдәге нифакъ. Алар үзләренең дөньяви максатларына ирешү өчен гомуми халыкка яхшы булып күренергә тырышсалар да, эчләрендә аларга карата нәфрәтлек саклыйлар.

**Дүртенчесе:**

Сәүдәдәге нифакъ. Хәзерге заманаларда, күп кенә сүәдәгәрләр башкаларның ышанычын яулап, Аллаһтан курыкмыйча, төрле алдау вә ялган юллары белән бер-берсенең малларын, акчаларын үзләштерергә тырышалар.

**Бишенчесе:**

Ярдәм вә хезмәт күрсәтүдәге нифакъ. Кемнәрдер мохтаҗларга ярдәм күрсәткән булып, үзләренә файда эзлиләр, мактаналар.

## 🕮 Пәйгамбәребезгә ﷺ кадәр булган монафикълар һәм аларның тарихтагы кабахәт күренешләре

**❁ Иблис – иң беренче монафикъ:**

Коръәннән билгеле булганча, иблис (Аллаһның ләгънәте аңа) иң беренче монафикъ булып санала.

Мәгънәсе: **«Аларга шәйтан вәсвәсә кылды, аларның ябык гаурәтләрен ачмак өчен һәм әйтте: «Аллаһ сезнең фәрештә булуыгызны теләмәгәне яки Җәннәттә мәңге калуыгызны теләмәгәне өчен сезне ошбу агачтан тыйды», – дип. «Тәхкыйк мин сезгә яхшылыкны телимен», – дип ант итте иблис. Алдап аларны агачка якын китерде. Алар агачтан ашадылар, гаурәтләре ачылды вә Җәннәт яфраклары белән гаурәтләрен капларга ашыктылар, аларга Раббылары кычкырды: «Ә! Мин сезне ошбу агачтан тыймадыммы? Вә тәхкыйк шәйтан сезгә ачык дошман, сакланыгыз, дип әйтмәдемме?» – дип. Адәм вә Һава әйттеләр: «Әй Раббыбыз, үзебезгә золым кылдык, әгәр безне ярлыкамасаң һәм рәхмәт кылмасаң, әлбәттә, бәхетсезләрдән булачакбыз», – дип. Аллаһ әйтте: «Әй, Адәм белән иблис, бер-берегезгә дошман булганыгыз хәлдә Җиргә иңегез! Сезгә торачак урын һәм әҗәлегезгәчә файдаланачак җай Җирдә». Аллаһ әйтте: «Җирдә тереклек итәрсез вә Җирдә үләрсез һәм Җирдән чыгарылырсыз».** (Әл-Әгъраф: 20-25)

Аллаһ тәгалә иблисне Үзенең рәхмәтеннән сөргәч, ул Адәмгә һәм аның хатынына бик тә каты нәфрәтле булды Һәм аларны Раббыларына гөнаһлы итәр өчен үзенең мәкерлекләрен кыла башлады. Адәм белән

Хәвә янына нифакъ киеме киеп, антлар итә-итә аларга яхшылыкны гына теләүче үгет-нәсыйхәтче кебек килде һәм аларны Аллаһ тыйган агачтан ашатып фәрештә яки мәңге Җәннәтле булулары белән алдады.

Шулай итеп иблис, галәмнәрдә иң беренче булып монафикълык вә икейөзлелек киемен башлап җибәрде һәм монафикълар барсы да шәйтан гаскәре булды.

**۞ Яһүд монафигы – Шәүүл, христиан динен кабул иткәннән соң – Бүлс исемле:**

Христиан диненә бик зур зыян китергән кешенең исеме яһүд монафигы Шәүүл була. Ул Гыйсә عليه السلام заманында яшәсә дә, аны күрми һәм Гыйсәгә عليه السلام иман китереп ияргән кешеләрнең иң зур дошманы, аларны газап кылучы вә үтерүче булып санала.

Ибен Хәзм «әл-Фасл фил-миләл»дә искә алып узганча, Гыйсә عليه السلام күккә күтәрелгәч, яһүдләрнең гыйлем иясләре Бүлсне акча белән алдалап, христиан динен кабул итәргә кушалар. Алар араларына кереп Гыйсәнең عليه السلام иярченнәрен адаштырырга вә Бүлснең үзен имеш Гыйсәнең عليه السلام әмере белән иләһ итеп куелган икәнлеген игълан итәргә боералар. Шушы гамәлләре белән Бүлс, Аллаһ Гыйсәгә عليه السلام иңдергән динне бозырга тиеш була. Бүлс үзенең икейөзлелеге белән христианнарны Гыйсәнең عليه السلام диненнән читләштереп, алар арасына зур фетнә кертә вә асыл динне бозуга шактый сәбәпчел була. Аңа күпчелек гыйлемсез, надан халык ияря һәм шул сәбәпле аз санлы хакыйкый диндә булганнарны таркатуда зур уңышларга ирешә.

## 🕮 Пәйгамбәребез ﷺ вакытында һәм аннан соң булган кайбер монафикъларның исемнәре һәм аларның тарихтагы кабахәт күренешләре

**1) Мәдинә монафикъларының башлыгы – Габдуллаһ бин Үбәй бин Сәлүл:**

Габдуллаһ бин Үбәй бин Сәлүл Мәдинәгә Ислам килгәнче әл-Хазраҗ кабиләсенең билгеле вә затлы кешеләреннән була.

Ибен Исхак, Гасыйм бин Гомәр бин Катәдәдән риваять итеп болай диде: «Пәйгамбәребез ﷺ Мәдинәгә килгәндә, Габдуллаһ бин Үбәй бин Сәлүл әл-Гауфий үзләренең кабиләсендә билгеле вә затлы әфәнде иде. Әл-Әүс вә әл-Хазраҗ кабиләләре Ислам килгәнче аннән башка беркем астында да бердәм җыелмаган булалар һәм аны үзләренең патшалары итеп куясы иделәр. Ләкин Аллаһ тәгаләә аларга расүлен китерде һәм ул кавем Исламга күчте. Габдуллаһ бин Сәлүл патшалыкның кулыннан киткәнен күреп, Исламга вә пәйгамбәребезгә ﷺ бик каты нәфрәтләнде, ләкин кавеме аннан борылып Исламга күчкәч, ул инде нәфрәтлелек вә икейөзлелек белән булса да Исламга керде».

۞ Үсәмә бин Зәйд бин Хәрисәдән ؓ риваять ителәә: «Сәгъд бин Губәдәһ ؓ авыргач пәйгамбәребез ﷺ фәдәк[30] тукымасы белән капланган иярле ишәгенә утырды да, аны зиярат кылырга юнәлде. Мине ул ﷺ үзенең артына утыртты. Барганда, Мүзәхим исемле каланчасының[31] күләгәсендә торган, Аллаһның дошманы ибен Үбәй яныннан узарга туры кил-

30 «Фәдәк» исемле җирдә ясалган тукыма

31 Башня

де. Аның тирәсендә кавеменең кешеләре бар иде. Пәйгамбәребез ﷺ ибен Үбәйне күргәч, аның янына туктамыйча китүне хуп күрмәде, туктап ишәгеннән төште дә, аңа сәлам биреп беразга утырды. Расүле-без ﷺ Коръән укыды, Аллаһны искә төшерде, Аңа чакырды, Җәһәннәм белән куркытты, Җәннәт белән шатландырды һәм гөнаһлардан кисәтте. Пәйгамбәребез ﷺ нәсыйхәтләгәндә Габдуллаһ бин Үбәй дәшмичә генә тәккәбберләнеп утыра бирде. Расүлебез ﷺ сөйләп бетергәч, ул (Габдуллаһ бин Үбәй): «Син матур сөйлисең, ләкин әгәр дә син әйткән нәрсәләр дөрес вә хак икән, син өеңдә утыр һәм кем сиңа килә икән – шуңа сөйлә. Ә кем сиңа килми икән, аларның җыелышкан урыннарына барып тыңласы килмәгән вә яратмаган нәрсәләрен сөйләп кешене йөдәтмә. Шулай яхшырак булыр», – диде. Алар арасында булган мөселманнардан Габдуллаһ бин Рауәхәһ әйтте: «Юк! Син безнең янга, безнең җыеннарыбызга, йортларыбызга Коръән белән кил. Аллаһ белән ант итәм! Бу без яраткан нәрсә, шушы Коръән белән Ул безне хөрмәтләде һәм безгә һидәять бирде». Габдуллаһ бин Үбәй кавеме арасында капма-каршылык күреп болай диде:

«Синең әфәндең – синең көндәшең булганда,
Син һәрвакытта да түбәнсетелгән булырсың,
Һәм син каршы көрәшкәннәр сине җиңәрләр.
Канатсыз лачын күккә күтәрелә алырмы?
Әгәр дә беркөнне аның канатлары киселсә,
Ул һичшиксез егылып төшә».

Пәйгамбәребез ﷺ Сәгъд бин Губәдәгә رضي الله عنه килеп кергәндә йөзендә, Аллаһның дошманы ибен Үбәй бин Сәлүл әйткән сүзләрнең әсәре күренә иде. Сәгъд

әйтте: «Аллаһ белән ант итәм! Әй Аллаһның илчесе, мин синең йөзеңдә кайгы күрәм, сиңа берәрсе начар сүз әйттеме?». Пәйгамбәребез ﷺ: ***«Әйе»,*** – диде һәм аңа ибен Үбәй әйткән сүзләрне хәбәр итте. Сәгъд бин Губәдәһ ؓ әйтте: «Әй расүл Аллаһ! Син аңа карата йомшак бул. Аллаһ тәгалә безгә сине җибәргән вакытта, без аны патша итмәкче идек, ә ул сине аның патшалыгын тартып алды дип уйлый».

❁ Пәйгамбәребез ﷺ Бәнү Надыйр яһүдләрен хыянәтләре өчен камап алгач, Бәнү Гауф бин әл-Хазраҗ кабиләсеннән булган Габдуллаһ бин Үбәй бин Сәлүл, Мәлик бин Әбий Кауфәл, Сүәйд, Дәгис, Бәнү Үмәйәдән Үәдига бин Сәбит кебек Аллаһ дошманнары аларга яшерен яучыларын җибәрделәр. Бу төркем монафикълар Бәнү Надыйр яһүдләренә: «Нык торыгыз вә бирешмәгез! Без сезне сатмаячакбыз! Әгәр дә сезгә каршы сугыша башласалар, без сезнең якта (мөселманнарга каршы) сугышачакбыз! Ә инде сезне куып чыгарсалар, без сезнең белән бергә китәчәкбез!», – дип, яһүдләргә үзләренең теләктәшлекләрен белдерделәр.

Яһүдләр монафикълардан ярдәм көтә башладылар, ләкин тегеләре ярдәм күрсәтмәделәр. Аллаһ тәгалә Бәнү Надыйр яһүдләренең йөрәкләренә курку салды һәм алар пәйгамбәребездән ﷺ азат итүне һәм коралдан башка үзләре күтәрә алырлык нәрсәләрен генә алып Мәдинәне ташлап китәргә рөхсәт сорадылар. Расүлебез ﷺ риза лашты.

## 2) Әл-Җәдд бин Кайс:

Ибен Һишәмнең «әс-Сира ән-Нәбәүия» китабында болай диелде: «Пәйгамбәребез ﷺ Бәнү Сәлимә кабиләсеннән: ***«Сезнең әфәндегез кем?»,*** – дип со-

рагач, алар: «Саранлыгына карамастан әл-Җәдд бин Кайс», – диделәр. Пәйгамбәребез ﷺ аларга: ***«Саранлыктан да зуррак чир булырга мөмкинме! Бәнү Сәлимәнең чын әфәндесе — ак, бөдрә чәчле Бишр бин әл-Бәраә бин Мәгрур»,*** – диде».

❁ Һүдәйбия солыхы елында, пәйгамбәребез ﷺ белән гомрә кылырга чыккан мөселманнар арасында әл-Җәдд бин Кайс та бар иде. Ләкин курайш мөшрикләре мөселманнарны гомрә кылудан тыйдылар. Мәккәгә илче итеп җибәрелгән Госман бин Гаффанның ؓ үтерелгән хәбәре пәйгамбәребезгә ﷺ ирешкәч (чынлыкта ул үтерелмәгән була), ул: ***«Курайш мөшрикләренең кирәкләрен бирмичә, без китмәячәкбез!»,*** - диде, һәм кешеләрне үзенә бәйгать[32] бирүгә чакырды. Бу, "әр-Ридуан" бәйгате иде һәм мөселманнар монда чигенмәскә вә үлгәнче сугышырга дип бәйгать иттеләр. Пәйгамбәребез ﷺ белән бергә булган мөселманнардан барчасы да ант итте, ләкин алар арасында булган әл-Җәдд бин Кайс бер үзе генә бәйгать кылмый калды.

Җәбир бин Габдуллаһ ؓ аның хакында: «Аллаһ белән ант итәм! Мин аның бәйгать кылучы мөселманнардан дөясенең култык астына береккән кебек качып торганын күреп тордым», – диде.

❁ Пәйгамбәребез ﷺ мөселманнарга Румнарга каршы Табүк сугышына әзерләнергә боергач, әл-Җәдд бин Кайска: ***«Әй әл-Җәдд! Син бу елны Бәнү әл-Асфарга (румнарга) каршы сугышырга барасыңмы?»,*** – диде. Ул: «Әй Аллаһның илчесе! Миңа сугыштан калырга рөхсәт ит һәм мине фетнәгә салма! Аллаһ белән ант итәм! Кавемемнең барчасы да, хатыннарга карата миннән дә шәһвәтлесе юк икәнне

32 Тугрылык анты

белә, шуңа да, рум хатыннарын күрсәм сабыр итә алмасмын дип куркам», – диде. Пәйгамбәребез ﷺ аннан читкә борылды да: ***«Мин сиңа рөхсәт итәм»,*** – диде. Һәм бу хакта Аллаһ тәгалә ошбу аятьне иңдерде: **«Янә кайберләре әйтер: «Әй, рәсүлүллаһ! Миңа сугыштан калырга рөхсәт биргел! Мине фетнәгә салма», – дип. Алар күңелләрендә монафикълык чире булган өчен фетнәгә төштеләр. Җәһәннәм, әлбәттә, кәферләрне чорнап алучы».** (Әт-Тәүбә: 49)

Шулай ук, монафикълар җөмләсеннән искә алынганнар: Бәнү Зафардан Хәтыйб бин Үмәйә бин Рафигь, Кузмән, әл-Әүстән әл-Хәрис бин Сүәйд бин Самит, Нәбтәл бин әл-Хәрис, Мирбәгь бин Кайзый, Әүс бин Кайзый, Җүләс бин Сүәйд бин Самит, Әбү Тагьмә Бәшир бин Үбәйрикъ, Бәнү Үмәйәдән бин Зәйд бин Мәлик кабиләсеннән Үдига бин Сәбит, Габдуллаһ бин Сәбә‘, Мәймүн бин Дәйсан әл-Каддәх, ибен әл-Галькамий, Дүнмә яһүдләре...

# Эчтәлек


Кереш сүз........................................................2

Монафикълык һәм аның куркынычлыгы............6

Монафикъларның көферлек белән бәйле төрләре.6

Икейөзлелеккә этәрүче сәбәпләр.......................11

Нифакъның дәрәҗәләре...................................11

Кечкенә нифакъ (монафикълык)........................12

Сахәбәләрнең нифакътан саклanулары............14

Пәйгамбәребезнең ﷺ монафикъка биргән чагыштырмалары.............................................................21

Монафикъларның тәннәрендә чагылган кайбер сыйфатлары........................................................23

Икейөзлелек чагыла торган урыннар вә аның күренешләре...................................................24

Пәйгамбәребезгә ﷺ кадәр булган монафикълар һәм аларның тарихтагы кабахәт күренешләре............25

Пәйгамбәребез ﷺ вакытында һәм аннан соң булган кайбер монафикъларның исемнәре һәм аларның тарихтагы кабахәт күренешләре....................................27